

Зобәржәт - изумруд туй,  гаилә очен зур бәйрәм. Ярты гасырдан артык (55 ел!) инне-ингә куеп, кайгыны һәм шатлыкны уртак итеп, тормыш юлыннан атлау. Шундыйларнн берсе Варданян гаиләсе.

Бергә vткәргән еллар - чын байлык. Бу хәзинә ияләре - Румия белән Владимир Варданяннар. Зур тормыш юлында бер-берсенә хөрмәт, мәхәббәт саклый алганнар алар. Румия Али кызы тумышы белән Рузаевка районы Татар Пешләсе авылындагы кvпбалалы гаиләдән. Балачактан ук хезмәтне хөрмәт итеп яшәргә өйрәнгән кыз-бала 1958нчы елны урта мәктәпне тәмамлый. Тормыш биографиясен төрле эшләрдә хезмәт белән башларга туры килә ана. Почтада да эшли. Ә 1960нчы елдан лаеклы ялга кадәр Румия Али кызы бер оешмада -  Рузаевка горторгында сатучы, завсклад булып тырышып эшли.       Ә тормыш иптәше Владимир Ашотович, Армениядә туган. Әтисе Боек Ватан сугышында вафат булган. Озакламый кадерле әнисен дә югалта. Гаиләдәге бердән-бер ятим калган баланы әтисенен абыйсы гаиләсе тәрбияли. 1957нче елны Советлар Армиясе сафына, тимер юллар частенә, хезмәткә алына. Шулай ул Рузаевкага эләгә. Мотовоз машинисты булып сержант дәрәжәсенә житә. Хезмәтен тәмамлап туган ягына кайта ул, әмма анда эшкә урнаша алмагач, янадан тимерюлчылар шәһәренә, Рузаевкага килә. Владимир Ашотович гомере буе тимерюл энергоучастогында мотовоз машинисты булып хөрмәтлеләр рәтенә баса.

Мәхәббәт ул киноларда һәм китапларда тормыштан алып языла. Румия Али кызы vзенен гомерлек сөйгәнен Рузаевка вокзалыннан ерак булмаган Иске базарда очрата. Шул вакыт анын горторгта эшләп йөргән чагы. Румия туташ эшләгән кибеткә дусты белән Владимир егет керә һәм курчак төсле матур, сөйкемле  кыз белән таныша. Мизгелләр эчендә бер-берсенә гашыйк булалар – язмыш, ахрысы. Бер ел бергә дуслашып эштән сон киноларга, тимерюлчылар клубына танцыларга йөргән чакта кияv белән кәләшкә әйләнеп киткәннәрен сизми дә калалар. Шулкадәр матур, зур хөрмәт һәм соклану белән аралашулары олы мәхәббәт булып кабына. Әмма юлларына киртә чыга, ул Румиянен әнисе бу дуслыкка каршы була, егетнен дә туганнары хупламый. Нәтижәдә мәхәббәт жинvче буларак тантана итә.

- Нишләп Владимир диярсез? Аны белгәннәре бик тә мактый иделәр, мина карата да бик игътибарлы булды, ихтирам белән карады. Әмма Әнием ризалашмады. Икәv сөйләшеп

загска бардык та 1962 нче елнын 18нче январендә монәсәбәтләребезне теркәдек, - дип уртаклашты Румия Али кызы.
Варданяннар ике бала тәрбияләп vстерәләр – Лида кызларын һәм Ашот улларын. Бvген дvрт оныклары: Игорь, Роксана, Руслан һәм Ольга. Барысы да бер-берсеннән ерак тvгел яшиләр, әти-әниләренен зур остәлләре артында бергә жыелышып аралашырга яраталар, унышлары белән уртаклашалар. Шул вакыт әниләренен пәрәмәчле чәе бигърәк тәмле була!
- Румиям хормәт итә белә, оста хужабикә, бер сvз белән әйткәндә – акыллы. Мин тормыш иптәшемнән ундым, мин бәхетле. Безнен кебек яшәсеннәр әле! Анын белән 100 ел бернинди ремонтсыз яшәргә була, - дип колеп ала Владимир Ашотович, монәсәбәтләр турында сорагач.
Румия Али кызы да vзен бәхетле дип саный: эштән сонга калып килгәндә, балалары тәрбияләнгән, пешкән ашы остәлдә, ой жыештырылган. Шундый ир турында хыялланган була да яшvсмер кыз Румия. Бернинди темага тавыш-гауга купмый. Яшьләргә vрнәк алар.

- Тормыш яме гаиләдә. Безнен очен ин кадерлесе - гаиләбез: балаларыбыз һәм оныкларыбыз. Яшьләр бездән vрнәк алсын: гаилә коргач, тавыш чыккан саен аерылышмыйлар бит! Тормышта торлесе була. Гомер итv - дингез кичv, диләр бит. Ә тормышлар тормый дулкынсыз. Башны да тарак шомартмый, тормыш шомарта, - ди Румия Али кызы Варданян.

**Н.Хәлил**